**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеменгерского сельского поселения**

422756, Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

422756, Атнинский муниципальный район
с.Большой Менгер, ул. Советская, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2024 ел. № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 09.00 сәгатьттә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында теркәлгән, Ленин урамы буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

1.1.2024 елның 22 ноябрендә 12.00 сәгатьттә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында теркәлгән, Пролетарская,Школьная һәм урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

1.2. 2024 елның 22 ноябрендә 15.00 сәгатьттә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында теркәлгән, Татарстан һәм Пионерская урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын өченче этабын билгеләргә.

1.3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны — Олы Мәңгәр авылы, Ленин урамы, 34 йорт, кибет;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү урыны — Олы Мәңгәр авылы, Советская урамы, 11 йорт, Олы Мәңгәр авыл мәдәният йорты;
- гражданнар җыенының өченче этабын үткәрү урыны — Олы Мәңгәр авылы, Советская урамы, 11 йорт, Олы Мәңгәр авыл мәдәният йорты.

1.4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Олы Мәңгәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Олы Мәңгәр торак пункты халкына массакүләм мәгълумат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

1.5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1 Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Олы Мәңгәр авылы аша узучы елга буендагы территориянең агачларын кисү һәм чистарту );

2. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру));”

3. Ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү ( Олы Мәңгәр авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү,чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)).”

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үл халыкка игълан ителган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Олы Мәңгәр
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Филатова